**СОВЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Коньяк урамы,1 нче йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2025 елның 05 ноябре** **16 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан җирлегенең Кече Кабан авылында (Большая, Весенняя, Вишневый, Лесная, Липовый урамнары, Мира тыкрыгы, Нестеров, Придорожная, Солнечная, урамнары Цветочная тыкрыгы территорияләрендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге Уставының 23 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан җирлегенең Кече Кабан авылында (Большая, Весенняя, Вишневый, Лесная, Липовый урамнары Мира тыкрыгы, Нестеров, Придорожная, Солнечная, урамнары, Цветочная тыкрыгы территорияләрендә) гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 17 ноябрендә 19 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1. 2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Лаеш муниципаль районы Олы Кабан җирлегенең Кече Кабан авылында (Большая, Весенняя, Вишневый, Лесная, Липовый урамнары, Мир тыкрыгы, Нестеров,Придорожная, Солнечная, урамнары Цветочная тыкрыгы территорияләрендә) яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасында укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2026 елда 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кече Кабан торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (Цветочная ур. - балалар мәйданчыгы);

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- тротуарларны төзекләндерү, ремонт (Үзәк урам, «Пятерочка» кибетеннән башлап, җөп як).

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Олы Кабан
авыл җирлеге башлыгы урынбасары А.И. Маков